КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 8 октябрь г.Казань № 870

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 сентябрь, 1150 нче, 2024 ел, 31 май, 390 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының 1 бүлегенең «Дәүләт программасын гамәлгә ашыруның бөтен чорында финанс белән тәэмин итү күләмнәре» юлының беренче графасына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

«Коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру» төбәк проекты паспортының 1 бүлегендәге «Төбәк проекты администраторы» юлының икенче графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«И.А.Гомзик».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин